ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
ЯҢА КОКШАН АВЫЛЫНДА ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

**2021 нче елның 13 нче декабрендәге 2 нче номерлы КАРАРЫ**

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Яңа Кокшан авылы халкы җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Яңа Кокшан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә кертергә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә

2. Җыелган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. зиратны чүп-чардан чистарту
2. балалар мәйданчыгын коймалау

3. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Кокшан авылы мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Монаш авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга. www.mendeleevsk.tatar.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Монаш авыл җирлеге Советы башлыгы Р.Ф.Иосифов